МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-Т0ЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ**
22.07.2019

Казан шәһәре

**БОЕРЫК**
**№** 151/2 - пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгы каршында
журналистларны аккредитацияләү
кагыйдәләрен раслау турында

“Массакүләм мәгълүмат чаралары турында” 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә боерам**:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршында журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Оештыру эше һәм социаль үсеш бүлеге башлыгы Э.Л. Борһановка Кагыйдәләрне Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2019 елның 22 июлендәге 151/2-пр номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршында журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләре**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Кагыйдәләр "Массакүләм мәгълүмат чаралары турында" 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – аккредитация, Министрлык) каршында массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү тәртибен регламентлаштыра.

1.2. Аккредитацияләүнең вакыты чикләнми. Массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенең теләге буенча аккредитация редакциянең конкрет биремен үтәү өчен кирәкле срокка йә аккредитацияләнгән журналист вакытлыча булмаган очракта аны алыштыру өчен (вакытлыча аккредитация) бирелә.

## II. Журналистларны аккредитацияләү хокукы

2.1. Аккредитацияләү хокукына, милек рәвешләренә һәм гамәлгә куючылар составына бәйсез рәвештә, барлык массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары ия була. Чит ил массакүләм мәгълүмат чарасы журналистын аккредитацияләү өчен аны аккредитацияләүне Россия Федерациясе Чит илләр эшләре министрлыгы каршында расларга кирәк.

## III. Аккредитацияләү тәртибе

3.1. Аккредитацияләүгә заявка Министрлыкка массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы белән, чара башлану көненә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бу заявканың Министрлык тарафыннан алыну фактын, датасын һәм вакытын раслый торган теләсә нинди ысул белән бирелә.

3.2. Заявкада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), эш һәм мобиль телефоннары, электрон почта адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкның датасы һәм номеры күрсәтелә. Чит ил массакүләм мәгълүмат чарасы журналистын аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Чит илләр эшләре министрлыгы каршында аккредитацияләүне узуны раслый торган документлар куела.

3.3. Министрлыкка әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән сроктан соңрак кергән заявкалар, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.3 пункты таләпләренә туры килми торган заявкалар каралмый.

3.4. Аккредитацияләү турында (аккредитацияләүдән баш тарту турында) карар Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры (аның

вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба - Министр) тарафыннан заявка кергән көндә кабул ителә. Мондый карар, тиешле чара башланырга ике сәгатьтән дә соңга калмыйча, заявканы җибәргән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә аның редакция тарафыннан алыну фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирә торган теләсә нинди ысул белән җиткерелә. Ашыгыч чара уздырылган очракта, кабул ителгән карар турындагы мәгълүматны җиткерү мондый чара башланыр алдыннан да башкарыла.

3.5. Аккредитацияләүдән баш тарту массакүләм мәгълүмат чарасы махсуслашкан очракта (реклама, белешмә, күңел ачу характерында булганда) гамәлгә ашырыла.

## IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәгеләргә хокуклы:

чарада катнашырга;

чара турында Министрлыкта булган рәсми документларның күчермәләрен (көн тәртибен, пресс-релизларны, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материалларны) алырга;

бастырып чыгару өчен билгеләнгән мәгълүмати-белешмә материаллар белән танышырга;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

чара регламентын үтәргә һәм аның барышына тыкшынмаска, әгәр ул массакүләм мәгълүмат чарасы өчен махсус оештырылмаган булса;

чарада катнашучылар эшчәнлегенә каршылык тудырмаска;

басылып чыга торган язмаларда (эфир эшендә) Министрлык тарафыннан бирелгән пресс-релизлардан, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материаллардан файдаланганда, мәгълүмат чыганагына сылтама бирергә;

үзенең һөнәри эшчәнлеген гамәлгә ашырганда Министрлык эшчәнлеге турында дөреслеккә туры килми торган белешмәләр таратмаска.